Җелеккә үткән «офсайд»

Тамашачы матч башланырга ике сәгать кала ук стадионга агылды. Буш урыннар берән-сәрән генә күренде. Җанатарлар үз эшен «бишле»гә башкарды. Үзебезнең команда булмаса да, стадионда утырган 34 372 кеше футболчыларның һәр хәрәкәтен көчле эмоцияләр белән үзенчә шәрехләде.

8 БИТ

Иң бөек бәйге

Татарстанның иң яхшы медицина хезмәткәрләрен бүләкләү тантанасы быел да күңелләрне тетрәндерерлек мизгелләргә бай булды. 2008 елда, ул чакта республиканың сәламәтлек саклау министры, бүген Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәрраховның җиңел кулыннан башланып киткән «Ел табибы – Ак чәчәкләр» бәйгесе быел унынчы тапкыр уздырылды. Чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

4 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 20.06.2017 | №65 (5827)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

«КЫЗЫЛ КАНӘФЕР» – ЯРДӘМ БИЛГЕСЕ

22 июнь – Хәтер һәм кайгы көне уңаеннан, Россиянең зур шәһәрләрендә «Память поколений» хәйрия фондының «Кызыл канәфер» акциясе уза.

Зөһрә САДЫЙКОВА

news.mail.ru

Озак еллар дәвамында Ватанны саклаучыларга хәтер һәм хөрмәтне аңлатып килгән әлеге символ хәзер безнең арада яшәүче ветераннарга ярдәм билгесе булып тора. Ягъни бу көннәрдә теләге булган һәркем «Кызыл канәфер» значогын сатып ала ала. Бәясе – 50 сум. Ә аннан кергән акчалар сугышчан хәрәкәтләрдә катнашкан һәм бүген ярдәмгә, тернәкләндерүгә мохтаҗ булган кешеләргә тотылачак.

Кампаниянең төп көне, әлбәттә, 22 июнь булачак. Бу көнне «кызыл канәфер» значогын күкрәгенә кадаган һәркем ветераннарга хөрмәтен күрсәтә һәм хәйрия традицияләре турында сөйли алачак.

– Күкрәгендә значок йөртүче һәр кеше ветеранга эш белән генә түгел, ә бөтен Россия буенча үткәрелә торган яңа традицияләр турында да мәгълүмат тарата. Шулай итеп, аны яңа бөтенхалык хәрәкәте буларак күрсәтүгә үзеннән зур өлеш кертә. «Кызыл канәфер» акциясе ярдәмендә без илебезнең бөтен кешесен – яшен-картын, ир-атын һәм хатын-кызын, мәктәп укучысын һәм студентын, пенсионерын һәм эшмәкәрен берләштерергә телибез. Әлеге значокны 22 июнь көнне генә түгел, ә башка вакытта да тагарга мөмкин, – ди «Память поколений» хәйрия фондының башкарма директоры Екатерина Круглова.

Значоклар май башыннан ук сатуга чыгарылган. Аларны хәйрия фондының партнерларыннан: «Магнит», «Окей», SELA, «Бәхетле», «Твой дом», «Алые паруса», BILLA, «7-я» кибетләреннән, шулай ук газета-журнал киоскларыннан сатып алырга мөмкин. Болардан кала, Сбербанкның корпоратив кибетләреннән дә табарга була.

Ә инде ветераннарга зуррак ярдәм итәргә теләге булганнар бу игелекле эшне «Память поколений» фондының рәсми сайты аша башкара ала. Шунда ук үзегез тапшырган акчаларның кемгә барып ирешүе турындагы мәгълүматны да белергә мөмкин.

Мәгълүм булганча, әлеге фондның президенты – Җир шарының беренче хатын-кыз космонавты, Советлар Союзы Герое Валентина Терешкова. Фонд ике ел эшләү дәверендә 3000 ветеранга югары технологияле медицина ярдәме күрсәткән: тернәкләндерү чаралары (инвалид арбалары, ходункилар, күп функцияле караватлар һәм башкалар) алынган, протезлар куелган. Бөек Ватан сугышында, Төньяк Кавказда террорчыларга каршы операцияләрдә, Әфганстандагы һәм Сүриядәге сугышчан хәрәкәтләрдә катнашканнар өчен шушы акциядән җыелган акчаларга дарулар, медицина җиһазлары сатып алына, тернәкләндерүдә ярдәм күрсәтелә.

Фондның Попечительләр советына Мария театрының сәнгать җитәкчесе Валерий Гергиев, Зур театрның прима-балеринасы Светлана Захарова, отставкадагы генерал, профессор Мәхмүд Гәрәев, спортчы һәм җәмәгать эшлеклесе Алина Кабаева, җырчы Иосиф Кобзон һәм башка бик күп танылган шәхесләр керүе дә зур мәгънәгә ия.

→ Теманың дәвамы 6нчы биттә.

Мең литр уха пешерделәр

tatarstan.ru

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Россия авыл хуҗалыгы министры урынбасары – Балыкчылык буенча агентлык җитәкчесе Илья Шестаков узган атнада «Казан» гаилә үзәге каршында оештырылган «Фишка» гастрономия фестивалендә булдылар. Фестиваль мәйданчыгында танылган Россия шоумены Оскар Кучера һәм Казан рестораны шеф-повары Максим Агуреев мең литр «Зур Казан уха»сын әзерләде. Зур учакта бөтен кеше күз алдында әзерләнгән ухаңы теләгән һәркем татып карады. Балык ярминкәсендә, Татарстан заводларында балык үстерүчеләр белән гәпләшеп, Рөстәм Миңнеханов белән Илья Шестаков, Кучерага һәм Агуреевка кушылып, уха пешерә торган зур казанга балык кисәкләрен салды. Соңыннан алар фестивальнең тематик мәйданчыкларын карадылар, тимерче чатырында булдылар. Биредә Илья Шестаков балык рәвешендәге сувенир чүкеп ясады.

Фестивальдә «Агач эшләнмәләр», «Керамика», «Татарстанның урман үләннәре», «Чүлмәкчелек» һәм башка мәйданчыклары да оештырылган иде.

Биредә балык сату ярминкәсе дә оештырылды. Арча, Кайбыч балык хуҗалыклары, «Батыршин» крестьян-фермер хуҗалыгы тере балык китергән, аның өчен аквариумнар куелган. Шулай ук балык шулпасы, кыздырылган балык тәкъдим иткән павильоннар бар иде.

Шул ук көнне Татарстан Хөкүмәте йортында Рөстәм Миңнехановка Татарстанның аквабиокультура комплексы проектын тәкъдим иттеләр. Киңәшмә Татарстанның балык хуҗалыгы тармагына багышланды һәм Казанда эшлекле сәфәрдә булган Россия авыл хуҗалыгы министры урынбасары – Балыкчылык буенча агентлык җитәкчесе Илья Шестаков катнашында үтте.

Проект, Татарстанда чит ил инвесторларын җәлеп итеп, балык үрчетүне күзаллый. Аерым алганда, Норвегия инвесторлары Татарстан белән әлеге проектны тормышка ашыруда кызыксынуларын раслаган.

Атлантика сөләйман балыгы, керкә, җәен – әлеге балыклар республикада үрчетелә башлаячак дип фаразлана. Хуҗалыклар Кама Аланында, Чистайда һәм Зәйдә булыр дип күзаллана.

Федераль юл агентлыгы җитәкчесе Роман Старовойт Казан – Новосибирск маршруты буенча федераль юл буйлап эш сәфәре вакытында күп функцияле «Ирбис» юл сервисы объектын карады, дип яза «Татар-информ».

«Ирбис» объекты югары бәяләнде

Комплекс М7 «Волга» автомобиль юлының 843нче чакрымында урнашкан. Ул үз эченә авыр һәм җиңел йөк машиналарын, реанимобиль һәм медицина катастрофа хезмәтенең вертолетларын кую урынын да ала. «Транзитсити» (Irbis) компанияләр группасы финанс директоры Роман Фатыйхов сүзләренчә, федераль трасса буйлап хәрәкәт иткән машиналарның йөртүчеләренә медицина ярдәме кирәк булуы ихтимал.

– Аларның шәһәргә кадәр барып җитәргә мөмкинлеге булмый. Ашыгыч ярдәм кирәк булганда исә вертолетка төшеп утыру өчен парковка да бар, – диде ул журналистларга.

Объект территориясендә ягулык салу станциясе, бәдрәф, душ, кер юу биналары, кафе, медицина кабинеты да эшли.

– Бер урында әллә ничә төрле хезмәт күрсәтелә. Киләчәктә кунакханә төзү уе да бар. Шиномонтаж өчен яңа бина төзү дә каралган. Проект юл сервисы объектларын үстерү концепциясе кысаларында гамәлгә ашырыла, – ди Фатыйхов.

Мондый объектлар Россиянең алты төбәгендә бар. Иң беренчеләре Татарстанда барлыкка килгән, аннары Чувашиядә, Түбән Новгородта, Владимир, Пенза өлкәләрендә, Мари Эл республикасында. Якын киләчәктә Чаллыда ачылачак. Республика буенча аларның саны – 17, ә Россия буйлап – 38.

Роман Старовойт машина кую урынын, ашыгыч ярдәм кареталарын карады, вертолетның техник характеристикасы белән кызыксынды, «Ирбис» юл сервисы объектын югары бәяләде.

ХӘРӘКӘТ ИМИНЛЕГЕ

Ял иткәндә дә кагыйдәне онытма

Казан шәһәре буенча эчке эшләр идарәсенең ЮХИДИ бүлеге ата-аналарны җәйге каникул чорында балаларга нык игътибарлы булырга чакыра. ЮХИДИ бүлегенең пропаганда хезмәткәрләре үзәре дә балаларның җәйге сәламәтләндерү лагерьларында юл хәрәкәте иминлеге темасына лекцияләр үткәрәләр. Чираттагы очрашу «Заречье» һәм «Спутник» лагерьларында булды. Балалар уеннар һәм викториналар аша юл хәрәкәте кагыйдәләрен искә төшерделәр. Тематик күнекмәләрне кабатлап тору мөмкинлеге бар. Автоинспекторлар лагерьларга юл хәрәкәте кагыйдәләрен уен аша өйрәнү әсбаплары, ә балаларга яктылык кайтара торган элементлар бүләк итте.

Социаль ипотека фатирларының бәясе артмаячак

vk.com

Татарстанда социаль ипотека программасына ихтыяҗ арта бара. Әлеге программа гамәлдә вакытта республикада 91 мең гаилә торак шартларын яхшырткан. Барлыгы 6 мең фатирга исәпләнгән 635 йорт төзелгән.

Президент каршындагы Дәүләт торак фондының мәгълүмати сәясәт төркеме җитәкчесе Гүзәл Рәхмәтуллина әйтүенчә, социаль ипотека программасы быел да тулы көченә эшләячәк. Тагын бер яңалык – тапшырыла торган фатирларның квадрат метры өчен бәяләр артмаячак.

– Республикада 150 гаиләне якынайтылган чираттан Дәүләт торак фондының төп реестрына күчерделәр. Бу – Чаллыдан – 103, Азнакайдан – ун, Зәйдән – биш, Лениногорскидан – 14, Лаештан – 13, Мамадыштан – биш гаилә. Киләсе өч елда әлеге гаиләләр фатирлы булыр дип көтелә. Аларга 1 сентябрьгә кадәр социаль ипотека килешүе төзергә туры киләчәк, – ди Гүзәл Рәхмәтуллина.

Социаль ипотека программасы бер урында гына тормый, гел яңара, камилләшә. Әле менә шушы көннәрдә дә Татарстанның Министрлар кабинеты тарафыннан чыгарылган карарга үзгәрешләр кертергә уйлыйлар. Аның нигезендә программада катнашучылар нотариаль килешү нигезендә фатирдагы өлешләрен үзләре билгели алачак. Хәзерге вакытта өлеш һәр катнашучыга да тигез бүленә.

2017 елда социаль ипотека программасына 17,6 миллиард сум акча каралган. Нәтиҗәдә 10 мең фатирга исәпләнгән 223 йорт кулланучыга тапшырылыр дип ниятләнелә. Киләсе елга – 13 мең, 2019 елда 9 мең фатир сафка басар дип көтелә.

Җитәкчелекнең хәсрәте – сентябрь

Казанда йортларны һәм биналарны җылылык белән тәэмин итә торган үткәргечләрнең гомум озынлыгы – 1842 километр. Кичә «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә башкала мэры Илсур Метшин: «Бу – Питердан Астанага кадәр ара», – дип, сүз белән, ике шәһәрне үткәргеч торбалар белән «ялгап» куйды.

Дамир БӘДРИЕВ

livejournal.com

КЫШКА ӘЗЕРЛЕК

– Быел җәй һаман башлана алмый азаплана. Май аенда балалар бакчаларына һәм медицина учреждениеләренә кабат җылылык җибәрергә туры килде. Мондый очракны хәтерләмим. Климат үзгәрешләре моннан ары инде гайре табигый хәл сыйфатында кабул ителмәс. Казанда торак фондны кышкы чорга әзерләү барышы югары дәрәҗәдә, – диде Илсур Метшин.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе Искәндәр Гыйниятуллин докладында әйтелгәнчә, Казанда киләсе кышкы җылыту чорына күпфатирлы 5685 йортны, 5306 бинаны, 802 социаль учреждениене, шул исәптән 195 мәктәпне һәм 355 балалар бакчасын әзерләү бурычы тора.

Эш колачы зур. «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Казан җылылык челтәре» – гомум озынлыкта 47 километр үткәргеч торбаларны капиталь төзекләндерергә тиеш. «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте үзенең карамагындагы алты котельныйга реконструкция башлаган, җиде километрда җылылык һәм җылы су үткәргечләрен яңартачаклар. «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – «Казан электр челтәре» коллективына һавадагы һәм җир астындагы 117 километр электр үткәргечләрне, 121 трансформаторны капиталь төзекләндерү йөкләнгән.

Капиталь ремонт программасы кысаларында, быел күп фатирлы 130 йортта, 12 мәктәптә, тугыз балалар бакчасында һәм 53 сырхауханәдә җылылык челтәре яңага алмаштырыла.

– Күп фатирлы 1115 йортка үз җылылык пунктлары көйләнелә. Әлеге казаннар фәкать җылы су гына әзерли. Аларның йорттагы җылылык челтәренә һәм җылылыкны тышкы һава температурасына карата көйли торган механизмга бернинди катнашы юк. Җылылык өчен түләүләргә дә бернинди катнашы юк, – диде Искәндәр Гыйниятуллин соңыннан журналистлар белән әңгәмәсендә.

Йортларны һәм биналарны кышкы чорга әзерләү – 1 сентябрьгә, ә әзерлек паспортларын булдыру 1 октябрьгә тәмамланырга тиеш. Әзерлек паспорты булмаган йортларга җылылык җибәрелми. Искәндәр Гыйниятуллин идарәче компанияләргә, подрядчы оешмаларга графикны төгәл саклау кирәклеген искәртте. Гадәттә, торак милекчеләре ширкәтләре (ТСЖ) әзерлек паспортлары булдыруга соңга калып керешә. Узган ел җылыту чоры башланының тәүге атналарында казанлылардан «Ачык Казан» («Открытая Казань») хезмәтенә 45,8 мең гариза һәм шикаять кергән.

ЭШКӘ БИЛГЕЛӘҮ

Кемнәр кем булды?

Казан мэры Илсур Метшин кичә «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә шәһәр Башкарма комитетында кадрлар үзгәрешләре белән таныштырды.

Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсен җитәкләгән Владимир Фомин мэр киңәшчесе итеп күчерелде. Илсур Метшин, бу үзгәртүнең максаты – муниципаль хезмәт күрсәтүләрдә «бердәм тәрәзә» оештыруны тизләтү зарурлыгы, дип аңлатты. Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе җитәкчесе итеп моңа кадәр тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсен җитәкләгән Ирина Дябилкина билгеләнде. Аның урынын тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсе җитәкчесе урынбасары булып эшләгән Әскар Баһаветдинов алды.

«Парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе итеп Алсу Карякина билгеләнде. Мэр Илсур Метшин сүз уңаенда әйтеп үткәнчә, соңгы берничә елда Казанда 53 парк һәм сквер төзекләндерелгән.

МОХИТ

Урицкий паркына хыялланырга кил

Татарстанның иҗтимагый мохитне үстерү программасы нигезендә, Казандагы Урицкий исемендәге паркны төзекләндерүнең өченче этабы башлана.

Бу паркны яңартуга моннан ике ел элек керештеләр. Ясалма күлнең төбе ләмнән һәм чүпчардан чистартылды, ярлар табигый ташлар белән ныгытылды, агач басмалар һәм пирс ясалды. Спорт мәйданчыгы эшләнде, балалар уен мәйданчыгы зурайтылды.

«Антошка» кафесы урынындагы җәйге сәхнәдә бүген 19.00 сәгатьтә Урицкий исемендәге паркны эчтәлек ягыннан баету мәсьәләсендә җәмәгатьчелек белән фикер алышу була. Әлеге чарада Татарстан Республикасы Президенты киңәшчесе Наталия Фишман белән Киров һәм Мәскәү районнары хакимияте башлыгы Сергей Мироновның катнашуы көтелә. Evolution агентлыгы архитекторы Антон Цыбисов үзенең проектын тәкъдим итә.

Табиблар да футбол сагында

tatar-inform.ru

Конфедерацияләр Кубогында медицина ярдәме өчен җавап биргән Республика клиник хастаханәсе, Казанның 7нче клиник хастаханәсе ФИФА оештыручыларыннан югары бәя алган. Татарстанның сәламәтлек саклау министры Адел Вафин сүзләренчә, республика Кубокка яхшы әзерлек белән килгән.

– Без Универсиада, Дөнья чемпионатлары вакытында тәҗрибә тупларга өлгердек. Республиканың 222 медицина хезмәткәре Сочида узган Олимпиада, паралимпиада уеннарында эшләде, – ди министр.

Конфедерацияләр Кубогының баш табибы Арслан Вәлиев сүзләренчә, ФИФАның таләпләре Олимпиадага караганда да катгыйрак. Дарулар исемлегеннән башлап, ашыгыч ярдәм машинасы килү, ярдәм күрсәтү вакытына кадәр контрольдә. Медицина хезмәткәрләре исә спортчыларга ярдәм күрсәтү өчен махсус дәресләр алган.

Бүген Кубокта барлыгы 385 медицина хезмәткәре эшли. Уен көнендә 130 белгеч кизү тора. Матчлар башланыр алдыннан 5 июнь көнне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов заманча 45 ашыгыч ярдәм машинасы ачкычы тапшырды. Дөнья чемпионатында да алар эшләячәк. Матч көннәрендә «Казан-Арена»да 11 ашыгыч ярдәм машинасы кизү тора. Тагын бишәр машина спортчылар яшәгән кунакханәләрдә, чикләү территориясендә хезмәт күрсәтә.

2 июньнән Кубокта эшләгән табибларга 245 тапкыр мөрәҗәгать иткәннәр.

– Башлыча, оештыручылар, Кубокта эшләгән кешеләр мөрәҗәгать итә. Әйтик, табиб күзәтүе астында булганнарның 16сы – ФИФА кешесе, 9ы – волонтер, 2се – журналист, 32се – тамашачы. Гадәттә, баш авыртудан, кан басымы күтәрелүдән, ОРВИдан зарланалар. Имгәнүчеләр дә булды. Нинди генә авырулар белән мөрәҗәгать итсәләр дә, даваларга бөтен әйберебез бар, – диде Адел Вафин.

Һәр зур чарадагы кебек, бу юлы да Казан ВИЧ-инфекциясенә тикшерену үзәге ачкан. Шулай итеп, 28 июньгә кадәр «Родина» кинотеатрында бушлай тикшеренеп була. Универсиада вакытында читтән килгән җанатарларда «экзотик» авырулар да ачыкланган булган. Министр сүзләренчә, әлегә Кубокта андый очрак күзәтелмәгән.

Алисә САБИРОВА.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

ИҢ БӨЕК БӘЙГЕ

Татарстанның «Ел табибы»н билгеләделәр

Татарстанның иң яхшы медицина хезмәткәрләрен бүләкләү тантанасы быел да күңелләрне тетрәндерерлек мизгелләргә бай булды. 2008 елда, ул чакта республиканың сәламәтлек саклау министры, бүген Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәрраховның җиңел кулыннан башланып киткән «Ел табибы – Ак чәчәкләр» бәйгесе быел унынчы тапкыр уздырылды. Чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

– Авыру гына түгел, бәхетле, озын гомер итәргә теләгән сәламәт һәркем табиб күзәтүе астында булырга тиеш. Медицина өлкәсендә зур проектлар гамәлгә ашырыла. Киләсе ике елда 197 объект төзекләндереләчәк. Без тәзибез, ниндидер заманча җиһазлар сатып ала алабыз, әмма һөнәри осталык, тәҗрибә, яхшы мөгамәләне бернәрсә дә алыштыра алмый. Медицина системасында иң мөһиме – кеше, – диде Президент.

Эльвира МОЗАФФАР

«БЕЗГӘ ҺӘР АВЫРУ КАДЕРЛЕ»

Быел бәйгедә катнашырга 146 гариза кабул ителгән. Җиңүгә дәгъва кылучылар биш номинация буенча билгеләнде, һәрберсендә өч лаеклы кандидатура тәкъдим ителгән иде. Бары **«Сәламәтлек саклау өлкәсендә легенда»** номинациясендә генә бер фамилия аталды – Раиса Гуслякова. 50 ел сәламәтлек саклау өлкәсендә эшләгән, бүген дә Республика клиник хастаханәсенең баш табибы урынбасары булып хезмәт итүче Россиянең, Татарстанның атказанган табибын Президент Рөстәм Миңнеханов үзе котлады.

– Үзгәртеп кору еллары кичердек, авырлыклар очраса да, медицинаны саклап калдык. Ә иң мөһиме – дәрәҗәбезне төшермәдек. Бер-беребезне, тормышны, үзебезне яратып яшик, – диде Раиса ханым, рәхмәт сүзләрен җиткереп.

«Елның медицина хезмәткәре» исеменә Республиканың йогышлы авырулар клиник хастаханәсендә кимчелекләр белән һәм җитлекми туган балалар бүлегендә эшләүче шәфкать туташы Гөлия Закирова лаек дип табылды.

– Мин бу һөнәрне сайлавым белән горурланам. Кеченә кешегә ярдәм итә алуым белән бәхетлемен, – ди Гөлия ханым.

Ул ВИЧ-инфекцияле ата-аналардан туган балаларны беренчеләрдән булып тәрбияләргә алынган. Аларны дүрт-биш яшькә кадәр үстерүне үз җаваплылыгына алган. Ягымлы карашы, җылы сүзе, эш осталыгы өчен аңа күпләр рәхмәтле.

«Елның медицина хезмәткәре» – иң халыкчан номинациядер, мөгаен, шуңа да шәфкать туташын котларга сәхнәгә Татарстанның халык артистлары Венера Ганиева белән Салават Фәтхетдинов җитәкләшеп чыктылар. Быел «Ак чәчәкләр» бәйгесендә беренче тапкыр алар дуэт башкарды. Сүз уңаеннан, Татарстан Президенты ярдәмчесе Ләйлә Фазлыевәны да беренче тапкыр алып баручы ролендә күрдек.

Беренчел медицина звеносын модернизацияләү һәм ныгытуга республикада зур урын бирелә. Авыруларны башлангыч стадиядә билгеләү, бу тармакта эшләүчеләрнең тәҗрибәсе, осталыгы – медицинаның ярты уңышы. Казанның 8нче Ашыгыч медицина ярдәме станциясе җитәкчесе Елена Голубицинаның да төп максаты – авыруга ярдәм итү. IX сыйныфта укыган чагында ук медицина өлкәсендә эшли башлаган кызга йөзләрчә кеше гомерен саклап калырга туры килгән. Йокысыз төннәр, рәхмәтле караш... һәм менә иң зур бәя – **«Беренчел звеноның иң яхшы табибы»** исемен алу.

«Уникаль очрак» номинациясендә катнашучы табиблар белән сөйләшкәннән соң, алар башкарган эшләр белән танышкач, могҗиза барлыгына ышана башлыйсың. Республика балалар клиник хастаханәсе табибларының җиде айлык сабыйны үлемнән коткарып калулары турында «Шәһри Казан» газетасының алдагы саннарында язган идек. Табиблар коткарып калган пациентлар үзләре дә чарада катнаштылар. Без язган җиде айлык бала да бүген зур малай булган. Аның: «Миңа гомер бүләк иткәнегез өчен рәхмәт сезгә!» – дигән ихлас сүзләреннән күзләре яшьләнде. Ә «Уникаль очрак» номинациясендә Чаллыдан Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе табиблары төркеме җиңеп чыкты. Алар юл һәлакәтенә эләккән егетне тормышка кайтара алганнар. Бик күп катлаулы тән җәрәхәтләре алган Иван үлем хәлендә була. 15 операция, 100 литрдан артык дару эремәсе, 26 наркоз... Бүген Иван йөри, эшли, балалары өчен яраткан эти, хатынының терәге.

– Без көн саен эшкә киләбез. Ниндидер батырлык эшләрбез, уникаль очрак булыр дип уебызга да китермибез. Безгә һәр авыру якын, кадерле, һәр пациентның тормышы өчен көрәшәбез. «Ак чәчәкләр» бәйгесендә җиңү безне яңа үрләргә ашкындыра, – ди Чаллының Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсендә баш табиб урынбасары Резеда Кәримова.

ИҢ КАДЕРЛЕ БҮЛӘК – ЧИКЛӘВЕК

Иң дулкынландыргыч мизгел – **«Ел табибы»н** билгеләүдер. Бу номинациядә быел Казан дәүләт медицина академиясенең хирургия кафедрасы җитәкчесе Игорь Малков җиңде. 40 ел гомерен хирургия өлкәсендә яңа алымнарны үзләштерүгә багышлаган табиб әлеге бүләкне хезмәте өчен иң зур бәя дип саный. Габдрахман Әпсәләмов романындагы табиб өчен иң кадерлесе пациент бүләк иткән ак чәчәкләр булса, Игорь Малков өчен урман чикләвеге икән.

– Бер бабайга катлаулы операция ясарга туры килде. Соңрак аның карчыгы, рәхмәт йөзеннән, миңа бер пакет калдырып китте. Карасам – урман чикләвеге. Шуннан да кадерлерәк бүләкне хәтерләмим, – ди табиб.

Остадан бар да була, диләрме әле? Рәхмәт сүзләрен Игорь Малков җыр юллары аша җиткерде.

Ел табибын тәбрикләгән сәламәтлек саклау министры Адел Вафин чыгышында Татарстанда эшләве белән горурлануын әйтте.

– Һәр медицина хезмәткәренең тормышында батырлыкка урын бар. Республикада медицина өлкәсендә Президент ярдәме белән күп нәрсә эшләнә. Безнең өстә – зур җаваплылык. Халык ихтыяҗларын канәгатьләндереп, авыру мәнфәгатьләрен кайгыртып эшләргә тырышабыз, – диде министр.

Ел саен бер медицина хезмәткәренә Татарстан Президентының махсус бүләге – машина тапшырыла. Бу юлы «Лада Гранта» автомобиле ачкычлары Югары Ослан районы үзәк хастаханәсенең Никольский фельдшер-акушерлык пунктын җитәкләүче Алевтина Цыгановага бирелде. Көтелмәгән сөенечтән, Алевтина ханым күз яшьләрен тыя алмады. Көн саен эшенә 8 чакрым җәяү йөргән фельдшерга машина бик кирәк!

Аны авылда барысы да «доктор Аля», «җирдәге фәрештә» дип йөртә икән. 36 ел эшләү дәверендә күпләр өчен гаилә әгъзасына әйләнгән ул. Үзе дә: «Һәр пациентымның туган көнен беләм, кайгысын, шатлыгын уртаклашам. Беркайчан да авырмасак иде», – ди.

Бүләк дигәннән, бәйге җиңүчеләренә, нинди номинациядә җиңү яулауларына карап, акчалата премияләр, чит ил хастаханәләрендә стажировка узу мөмкинлеге, iPadлар, шифаханәгә юлламалар бүләк ителде.

Гадәттә, табибларның барысын бергә җыю бик авыр. Алар гел хезмәттә, кеше гомере сагында. Әлеге тамашада катнашу өчен Мәскәүдән махсус килгән Россиянең халык артисты Олег Митяев әйткәндәй, «ярый әле бүген барыбыз да бергә җыела алдык». Мәшәкатьләрдән арынып тору, күрешеп сөйләшү, тәҗрибә уртаклашу, алга таба яңа көч, дәрт белән эшләү өчен мондый чаралар кирәк. «Ак чәчәкләр» бәйгесе – табиблар өчен бәйрәм кебек. Кайчандыр Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев: «Ак чәчәкләр»не – иң бөек конкурс», – дигән иде. Һәрчак шулай булып калсын, медицина хезмәткәрләренең дәрәҗәсе югары бәяләнсен.

Кайда сез, милли кадрлар?

Шушы көннәрдә Рәшит Ваһапов исемендәге Халыкара татар җыры фестивале Кайгыртучылар советының чираттагы утырышы узды. Анда яшь башкаручылар конкурсы нәтиҗәләре һәм үсеш юллары турында гына сөйләшеп калмыйча, тулаем татар җыр сәнгате проблемаларына да кагылып уздылар.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев фикеренчә, республиканың музыка сәнгатен өйрәнү, үстерү турындагы дәүләт программасы булырга тиеш. Ул татар җыр сәнгатен үстерү буенча республика күләмендә зур эш алып барылуын, республика җитәкчеләре дә әлеге өлкәгә игътибар итүенә басым ясады. Разил Вәлиев «Үзгәреш җиле» фестиваленә дә үз бәясен бирде.

– Мин «үзгәреш» сүзе белән бик килешеп бетмим. Без үзгәрергә түгел, ә камилләшергә тиеш. Әгәр үзгәрсәк, башка милләт булабыз. Безнең җыр сәнгатенең нигезендә татар аһәңнәре булырга тиеш. Һәм әлеге камилләшү балалар бакчаларыннан башланырга тиеш. Система булган очракта гына чын мәгънәсендә камилләшү булачак. Бу очракта Европаны да өйрәнергә, шул ук вакытта Көнчыгышны да онытырга ярамый, – диде.

Татарстанның Рәшит Ваһапов исемендәге татар иҗтимагый фонды директоры Рифат Фәттахов быел фестиваль кысаларында үткәрелгән бәйге нәтиҗәләре турында сөйләде. Ул гаризаларның артуын билгеләп үтте, әмма сайлап алу этабын камилләштерергә, жюри составында да үзгәрешләр кертергә кирәклеген әйтеп узды.

– Сайлап алу турларында 122 кешенең катнашуы бик үк яхшы түгел, иң уңышлысы – 50 кеше. Әмма бездә лауреат булган кешеләрнең 90 проценты югалып калмый. Алар бүген сәхнә тота, – диде Рифат әфәнде.

Ул, бәйгенең яңалыгы буларак, быел эстрада номинациясе кертелүен әйтте. Әмма Совет әгъзалары әлеге номинациянең концертта тәкъдим ителешен һәм эстрада чыгышларының сыйфатын югары бәяләмәделәр. Алар:

– Эстрада җырларын кертү фестивальнең дәрәҗәсен берникадәр төшерде. Аранжировкаларның да камиллегендә сораулар бар иде. Мондый номерлар данлыклы Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залы өчен түгел, – дигән фикерләрен җиткерде.

Рифат Фәттахов хәбәр итүенчә, бәйге тагын ике елдан соң үткәреләчәк.

– Без вокалчылар конкурсын ел саен үткәрү фикерендә түгел. Ел саен зур җырчы табып булмый. Безнең максатыбыз – конкурстан бер-ике җырчы сайлап алып, ике-өч ел эчендә зур сәхнәгә чыгару. Бу вакыт таләп итә, – дип аңлатты ул.

Рифат Фәттахов конкурсның быелгы лауреатына концертта игълан ителгән автомобильнең тапшырылуын да әйтеп узды.

– Бу Рәнис Габбасовка гына, хәтта Ваһапов фестиваленә генә түгел, ә татар җырын профессиональ югарылыкта башкаручы өметле җырчыларга мөнәсәбәтне күрсәтә, – диде ул.

«МУЗЫКАЛЬ ТӘНКЫЙТЬ ЮК»

Музыка белгече Филүсә Арсланова фикеренчә, татар музыкасын саклау мәсьәләсе турындагы сөйләшүләр, башлыча, зарлануга, коры сөйләшүгә генә кайтып кала, тәпле анализлар юк дәрәҗәсендә. Җыр сәнгатендә һөнәри билгесезлеккә битарафлык хөкем сөрә, җыр башкару культурасы фәнни яктан өйрәнелми.

– Музыкаль тәнкыйть юк, шуңа күрә сәхнәгә теләсә кем менә. Эстрада, опера театрының милли режиссерлары юк. Җырлаучылар татар сәхнәсенә казинога барган кебек киенеп чыгалар. Аларны без туйганчы иркәләдек, хәзер җимешләрен татыйбыз инде. Саллы тәнкыйть булмау мәдәният кризисына китерә. Милли кадрлар әзерли торган Казан дәүләт консерваториясе милләткә турыдан-туры хезмәт итә, дип әйтеп булмый, – дип саный ул.

Журналист һәм Казан дәүләт консерваториясе укытучысы Гүзәл Сәгыйтова, Филүсә Арслановага җавап итеп:

– Фән юк дигән фикерегез белән килешә алмыйм. Бар ул, ә менә музыкаль тәнкыйть, чыннан да, юк. Музыка белгечләренең булганнары да язмаларын матбугат чарасында бастыра алмыйлар, чөнки газета-журналларга мөрәҗәгать итсәләр, аларның мәкаләләрен кире кагалар. «Безгә мондый кирәк түгел, халыкка якынрак булсын», – диләр. Халыкка якын булсын өчен, редакцияләр белгечләргә мөрәҗәгать итмичә, үз журналистларыннан яздырталар. Музыка белгечләренең күңелләре төшә дә башка өлкәгә эшкә урнашалар, – диде.

Аннан соң, музыка буенча дәүләт программасы булдырылса, ул берләштерүче көчкә ия булыр иде, дип саный Гүзәл.

– Һәрберебез нәрсә булса да эшләргә тырыша, әмма дәүләт программасы булмыйча, ниндидер җитди яңарыш күренмәячәк. 1934 елны Мәскәү консерваториясе каршында опера студиясе барлыкка килә. Иң саллы әсәрләр шушында язылган. Дәүләт программасы да шундый берләштерүче көчкә ия булыр иде, – диде.

Шушы теманы Татарстанның халык артисты, Татарстанның җыр һәм бию ансамбле дирижеры, Әухәдиев исемендәге Казан музыка көллияте укытучысы Венера Гәрәева да дәвам итте. Аның фикеренчә, Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган милли кадрлар республикага кирәкми.

– Консерваторияне нинди генә милли кадрлар тәмамламады! Артур Исламов, Илүсә Хуҗина һәм башкалар... Алар татар милләтенең чын йөзе булырга тиеш иде бит. Кайда алар? Тамада булып йөриләр, чөнки гаиләне тотарга кирәк. Йә дөнья гизеп акча эшлиләр. Бу бик кызганыч. Ә бит алар башта барысы да музыка көллиятен тәмамлыйлар. Без аларны зур өметләр белән чыгарып җибәрәбез. Алар күңелләре белән чын татарлар. Чиста, саф килеш чыгып китәләр, әмма тормыш диварына башларын бәрәләр дә юкка чыгалар. Үзләрен опера солисты итеп әзерләгән ул-кызларыбыз нигә опера театрына алынмый?.. Шуңа күрә хәзер Ваһапов фестивален ныгыту турында сөйләшергә тиешбез, чөнки иң яхшы кадрлар шунда тәрбияләнә. Икенчесе, үзебезнең милли театрыбыз булырга тиеш, – диде ул, ачынып.

ЛЕГЕНДА БЕЛӘН ХУШЛАШУ

17 июнь – шимбә көнне, татар халкы легендар җырчы Әлфия Авзалова белән хушлашты. Моң алиһәсен озатырга халык бик күп җыелган иде – 2000 тирәсе кеше булгандыр. Иртәнге сәгать сигездән үк килгәннәргә сәхнәгә менеп, Әлфия Авзалова белән хушлашу мөмкинлеге тудырылды. Хушлашырга килгәннәрнең барысы да күренекле җырчыбыз турында якты истәлекләре белән уртаклашты. Халык белән сәхнәдә саубуллашу Әлфия Авзалованың үз теләге иде, дип яза «Татар-информ».

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Якыннары, җырчыны яратып тыңлаган тамашачылар белән бергә, мәрхүмәне соңгы юлга озатырга республика җитәкчелеге дә килгән иде. Матәм митингында Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Президент Аппараты җитәкчесе Әсгать Сафаров, мәдәният министры Айрат Сибагатуллин һәм башкалар катнашты.

– Бүген бөек җырчыбыз Әлфия Авзалованы соңгы юлга озатабыз. Язмыштан узмыш юк. Рәхмәт, бүген күпме халык килде. Аңа мәхәббәт күренеп тора, артык сүз кирәк тә түгел. Ул безнең халкыбызның газиз баласы. Ятим бала һәрвакыт газиз бала. Халык аны үз кочагына алды, – диде Минтимер Шәймиев.

Ул Әлфия Авзалованың тавышына Александр Ключарев һәм башка шәхесләрнең дә сокланганын билгеләп узды. Минтимер Шәймиев җырчы тормышында филармониянең зур роль уйнаганын, табигатьтән бирелгән сәләтен ачуда ярдәме хакында әйтеп узды.

– Җыр сәнгатендә иң тирән эз калдырган шәхесләрнең берсе. Кешенең үзеннән тора: Әлфиянең җорлыгы, тырышлыгы, тормышта югалып калмавы шушы казанышларга барлыкка килүгә нык ярдәм итте. Булганның булганы булып чыкты ул. Илһам һәм Әлфия үз чорының бизәге, безнең мирасыбыз булды. Бөтен илне гизеп, күпме җырлар җырлап, халкыбызның моңын башкаларга җиткерү – моннан да зур эшләр кайда булыр? Әлфиянең таланты зур, ничәмә-ничә миллион кешеләргә хезмәт иткән кеше начар кеше була алмый. Бу – зур казаныш. Әлфиянең гомере – җырлап узган гомер. Моң патшабикәсе дию аңа зур бәһа дияр идем. Әлфия кирәк чагында 14 телдә җырлап бирә алган. Шушындый сәләтле кызыбызны соңгы юлга озатабыз. Андый шәхесләр сирәк бит ул. Татар моңы, башка телләрдә җырланганда да, үзенчәлеген югалтмый, – дип билгеләп үтте Минтимер Шәймиев.

Дәүләт Киңәшчесе бүген кайбер артистларның өлкән җырчыларыбызга игътибарлы булуын белдерде.

– Салават Әлфияне сәхнәгә җитәкләп йөрде. Мин моны үрнәк итеп әйтәсем килә. Шулай булырга тиеш. Безгә үзебезнең кадерне белергә кирәк. Бу безнең халкыбызга хас әйбер. Әлфиягә дә, балаларына да, аларның иптәшләренә дә рәхмәт. Син халкыбызның күңелендә бар һәм булачаксың, – дип төгәлләде Беренче Президент.

Актаныш муниципаль районы башлыгы Фаил Камаев исә районның үзәк мәдәният йортына Әлфия Авзалова исеме биреләчәген әйтте.

– Әлфия апаның җырлары мәктәпләрдә утырган һәр баланың, кырларда иген иккән абыйларның, Донбасс шахталарында күмер чапкан, сугыштан аяк-кулларын югалтып кайткан каһарманнарның күңелләрен елатты да, юатты да. Ул милләтне җырлатты да, милләтне елатты да. Ул – ватаныбызның сайрар сандугачы, – дип белдерде чыгышында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов.

Әлфия Авзалова турында фикерләрен шулай ук Татарстанның халык артисты Зөһрә Шәрифуллина, Татарстанның халык артисты Әзһәр Шакиров, Татар дәүләт филармониясе директоры Кадыйм Нуруллин да җиткерде.

22 ИЮНЬ – ХӘТЕР ҺӘМ КАЙГЫ КӨНЕ

Онытылмас еллар хатирәсе

1941 елны әти фронтка китә. Бүгенгедәй күз алдымда аны, гомумән күпләгән авылдашларыбызны озаткан көн. Авыл шау-гөр килә. Кемнәрдер елый, кемнәрдер аларны юата. Моңсу гына гармун тавышына кушылып җырлаулар ишетелеп тора.

Кыр капкасын чыккан чакта
Кутәрелде томаннар.
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар!

Бу – китүчеләрнең авылыбыз, аның халкы белән саубуллашулары. Әтиебез абыебыз Дамирны, мине җитәкләп кибеткә алып керә һәм мандолина сатып алып, безгә бирә: «Мин кайтканчы уйнарга өйрәнеп куегыз!» Без аның бу васыятен үтәдек. Абыебыз да, шушы көнне өйдә бабасы янында калган бер яшьлек Энгел дә, үсеп җиткәч, мандолинада уйнарга өйрәндек.

Менә китүчеләр, аларны Кләүле стансасына кадәр озата баручылар кибет каршындагы олауларга төяләләр. Кемнәрдер елый, кемнәрдер аларны юата. Әниебез дә әтине озата бара. Арбалар кузгала. Без елыйбыз. Әтиебезнең өлкән имчәктәш туганы Кыям абзый безне юата: «Еламагыз, балалар, еламагыз», – ди, ләкин үзенең күзеннән дә яшь ага. Озакламастан ул үзе дә китте һәм шул китүеннән әйләнеп кайтмады.

Әтиебез – романтик рухтагы, татар моңы белән сугарылган кеше. Бик матур җырлый торган булган.

Бездә аның сугыш кырларыннан язган хатлары сакланган. Кайвакыт аларны алып, кат-кат укыйбыз. Аларның һәрберсе сагыну хисләре белән сугарылган. 1943 елның 19 мартында язган хатын үзе яратып башкара торган

«Урал суы болын буе,
Сандугачлар сайрый болында,
Ташлар ватып,
таулар кичкәндә дә
Сез булырсыз минем уемда», – дип тәмамлаган. Шушы җырны мин үзем өчен генә, әтиебезне искә төшерә-төшерә җырлаштыргалыйм.

Хатлар, сугыш сәбәпләре аркасында, шактый соңарып килгәли, тиешле органнарның аларны тоткарлаган чаклары да була. Бездән һаман хәбәр булмагач, ул борчылып, рәнҗеш белдереп язган хаты да бар. Анда ул билгесезлектән аптырап елавын да яшермәгән. «Айга якын хат алмагач, еламый буламыни», – дигән.

Хатлары йә сугыш кырыннан, йә госпитальдән. Аларның соңгыларының берсе 1944 елның ноябрендә Латвиядә язылган. «Мин бу хатны, сугыш туктап торган арада, саз түмгәге өстенә куеп язам», – дигән.

Кайгы кәгазен алгач, әниебез ничәмә көннәр буе, без балаларына да әйтмичә, ут йотып йөргәндер. Елагандыр, ләкин ялгызы, бер үзе. Беребезгә дә белдермәстән.

Сугыш башлангач, әниебезне ул вакыттагы Шөгер районының иң зур авылларыннан булган Түбән Чыршылы авылына директор итеп билгеләделәр. Без сугыш елларын шунда үткәрдек. Мәктәптә 500дән артык бала. Барысының да диярлек әтиләре һәм туганнары фронтта.

Әнине партия оешмасы секретаре итеп тә сайлыйлар. Аның өстенә, халык арасында агитация эшләрен оештыру да йөкләнә. Укытучыларның барысы да аның тирәсендә. Барысы да агитаторлар. Укытучылар уру-сугу, җиләргу, салам өю кебек эш вакытларында да колхозчылар белән.

Хатлар, хатлар! Аларны укыганда тарих җанлана сыман, инде мәңгелеккә киткән якыннарыбыз терелгән кебек була. Менә әтиебезнең 1943 елның 19 мартында язган хаты. Ул аны үзе яратып җырлый торган җырдагы сүзләр белән тәмамлаган. Аның шушы җырны башкаргандагы моңлы тавышы колак төбендә яңгырап тора сыман.

Әтиебез җыр-моң белән сугарылган кеше булган. Аның дары исе сеңгән хатларыннан да сафлык, табигатькә соклану хисләре бөркеп тора. Фронттан, ике сугыш арасында язган хатыннан өзек китерми булдыра алмыйм.

«Әминә, менә бүген 9 май. Күрсәң иде мондагы урманны, кырларның матурлыгын! Урман тулы төрле чәчәкләр, ямь-яшел чирәм. Иртән сызылып таң атканда, кукеләр кычкыра, сандугачлар сайрый башлый, ә башкалары, тын торып, үзенә бер төрле ямь бирә. Элеккегечә, җиләкклә бардым. Андый җиләкне күргәнем юк иде. Монда җир җиләге юк икән, гел каен җиләге, кызыл материал япкан кебек, бер кеше дә җыймаган. Башта таптамыйча-нитмичә сокланып карап тордым. Мин әйтәм, хәзер шушы урынның башына Әминә белән балаларны китерер куйсаң иде дә, сөйләшә-сөйләшә, җиләк җыясы иде, дим...

Ярый, Әминә, 30-35 көннән бәрәңгегез өлгереп, әкренләп ашый башларсыз. Бәрәңге ашый башладык дигән хәбәрегезне ишетсәм, беркадәр булса да җаным тынычланыр иде. Кәҗәгез торамы, әзрәк балаларга сөт бирә аламы? Әминә, күзгә дошманнарны тар-мар иткәч, кайта башларбыз. Тизлек белән күрешергә теләп, сагынып, сәлам белән,

Риза. 9 май 1944 ел.»

Ләкин безгә күрешү насыйп булмады. Ул бер елдан соң булачак Җиңү бәйрәмен каршылый алмады. Латвияне фашистлардан азат итү өчен барган дәһшәтле сугышлар вакытында рота командиры Риза Шәйхетдин улы Таһиров һәлак була һәм Ауц өязенең Звани хуторында җирләнә.

1967 елның августында мин, шушы хуторны эзләп, Ригага килдем. Аннан автобуска утырып, Ауцка юнәлдем. Автобустагы юлдашларым латышлар, минем кая һәм нигә барганым белән кызыксындылар. Мин аларга, шушы җирләрдә һәлак булган әтиебезнең каберен эзлим, дидем. Алар кызыксынганнан-кызыксынса төштеләр. Мин исә аларга йөзгә җиткән бабабызның өч улының берсе дә илләренә әйләнеп кайтмаулары, тол хатыннарның өчәр, дүртәр бала белән калулары, бабабызның кайгы-хәсрәткә уралган рәвештә дөнья белән саубуллашуы хакында бәйнә-бәйнә сөйләдем.

Ауцта миңа, тулы белешмә алу өчен, Ригага республика хәрби комиссариатына барырга тәкъдим иттеләр. Һәм анда кемгә мөрәҗәгать итәргә икәнлеген аңлаттылар, бер полковникның исемен атадылар.

Миңа военкомат ябылганчы анда барып җитәргә һәм кич белән үк поездга утырып, Ригадан китәргә кирәк. Борчылам, чөнки көн ахырына якынлаша. Военкомат баскычы буйлап өскә чабам, ә сәгать инде алты тулган. Өске катлардан ашыга-ашыга, офицерлар аска агыла. Каршыма очраган һәрбер офицердан гафу үтенә-үтенә, фамилияләрен сорыйм. Янәсе, аларның миңа кирәклесе кырыеннан үтеп китмәсен. Шуларның берсе, арткы ягына борылды да, өстән төшеп килүче берсенә күрсәтеп: «Әнә ул, сезгә кирәк кеше», – диде. Бик күп кәгазьләрне тикшереп карап чыкканнан соң, әтиебезнең җәсаде Салдус шәһәренең туганнар каберлегенә күчереп күмелгәнлеген әйтте. Шатлыгым эчемә сыймый. Мин шушы мәрхәмәтле полковникка рәхмәтемне әйтеп, аның белән саубуллаштым һәм тимер юл вокзалына киттем.

Икенче ялны янә Латвиягә юнәләм һәм Ригада поездда төшү белән үк, Салдуска бара торган автобуска утырам. Андагы военкоматта ныклап исемлекләрне тикшергәннән соң, әтиебезнең мондагы туганнар каберлегендә җирләнгәнлеген әйттеләр. Анда киттем, ләкин мәңләгән исем арасында үземә кирәген күрмәдем. Һәм янә военкоматка килеп, исемлектә әтиебезнең фамилиясе күрсәтелмәгәнлеген әйттем. Шушы эшләр өчен җаваплы старшинадан бу хатаны төзәтеп, мәрмәр таштагы исемнәр тезмәсенә әтиебезнең исемен яздыруны, фотосын төшереп миңа җибәрүен үтенеп, аңа расходлары өчен акча да биреп калдырдым. Ул үтенечемне үтәячәгенә вәгъдә биргәч, тынычланып, Казаныбызга кайтып киттем.

Старшинадан хәбәр булмады. Ләкин эшен эшләгәндер, тик фотосын гына эшләтә алмагандыр дигән өмет белән, 1987 елны энем Энгел белән әниебезне Салдуска алып бардык. Әнине кунакханәгә урнаштырып, үзебез туганнар каберлегенә киттек. Ләкин мәрмәр таштагы исемлектә әтиебезнең исеме юк. Таптык теге старшинаны. Ык-мык килсә дә, хатасын төзәтергә җыенмаганлыгын аңладык. Киттек райкомга. Безне беренче секретарь кабул итте. Аңа хәлебезне аңлаттык. Ул шул ук мизгелдә военкоматка шалтыратып, кемнәрнедер пыр туздырды һәм хәзер үк әтиебезнең исем-фамилиясен нәкъ аларның үзләрендәге исемлектәге кебек итеп мәрмәр ташка язып куярга дип әмер бирде.

Әмернең үтәлешен барып тикшердек һәм әтиебезнең исемен күргәннән соң әниебезне каберлеккә алып килдек. Ул анда намаз укыды һәм шуннан җир алып кайтып, аңа гөл утыртып үстерде. Әниебез исән чагында гөл ел саен чәчәк атып, безгә әтиебезне искә төшереп торды.

Сулдан уңга: әтиебез кулында мин, уртада әниебез итәгендә энебез Энгел, уң кырыйда әниебезнең бертуган Фатыйх абыйсы кочаклаган Дамир абыебыз.

Индус ТАҺИРОВ,
тарих фәннәре докторы,
профессор, сәясәтче, Татарстан
Фәннәр академиясе академигы.

ПОЧТАДАН

Изге мәҗлес

Хак динебезнең ихласлы әһелләре, быел ураза ае буенча, мәчетләрдә ифтар мәҗлесләре уздырды.

Казанның Киров районында «Рамазан» мәчетендә дә, иганәчеләр һәм дини кардәшләребез ярдәме белән берлектә, сый-хөрмәтле ифтар мәҗлесләрен үткәрү гадәткә керде. Сәдака акчаларына сатып алынган җиләк-җимеш, тәм-том һәм башка ризыктәгамнәр белән тутырылган бүләк-пакетлар Югары Ослан районында картлар йортында яшәүче өлкәннәргә тапшырыла әзерләнде. Яшел Үзән районының Норлат авылы балалар йортында тәрбияләнүчеләр дә, иншалла, өлешсез калмаслар. Бу һәм башка мактауга лаек изге эш-гамәлләр Солтан хәзрәт җитәкләгән коллективның ихлас тырышлыгы белән башкарыла.

Ә менә республика ифтарына чакырулы 10 меңгә якын дин кардәшебез 15 июньдә Теннис академиясе сараена ташкын сыман агылды. Республикабызның авыл-шәһәрләреннән автобусларга төялеп килгән халыкны волонтерлар дип аталган яшь егет-кызлар елмаешып каршы алды. Кирәк кадәр мәгълүмат биреп, бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итте. Трибуналарны тутырып утырган халык Җәмил хәзрәт Фазлыев һәм башка хөрмәтле хәзрәтләребезнең тирән мәгънәле һәм үтемле вәгазьләрен тыңлап белемнәрен баетудан бик тә канәгать булды. Су кабып авыз ачып алгач, намаз укыдык. Меңләгән кеше сәҗдәдә... Бу манзараны күрү бәхетеннән, күзләрем шатлык яшьләренә чыланды. Халкыбызның гасырлар буе чарланган дини бердәмлеген күреп горурландым.

Ниһаять, унтугыз сәгать буе бер тәгам ризык капмый, бер тамчы су йотмый, Аллаһының ризалыгы өчен нәфесләрен тыеп торудан зур канәгатьлек кичергән ун мең мөэмин-мөселман кунак, өстәлләрне тутырып, авыз суларын китереп төрледән-төрле җиләк-җимеш, тәм-том һәм дин кардәшләребез зур-зур казаннарда әзерләгән, хуш исләр бөркеп торган пылау кебек ризыкларны, «бисмиллаһир-рахмәнир-рахиим» дип, кулына алды.

Әле 922 елның 21 маенда болгар бабаларыбыз ислам динен җан-тәннәре белән яратып үз иткән, аңа ихластан иман китергән. Мәшһүр ураза гаетен зурлап уздыру гадәте гасырлар буе тамыр җәеп ныгыган. Шул данлыклы ерак Болгар бабаларыбыздан алып бүгенге көнгә кадәр Аллаһының хак диненә тугры калып, илбасарлар ассалар да, киссәләр дә, утка яксалар да, зинданнарга ябып юк итсәләр дә, милләтебезнең асыл затлары илгә дә, дингә дә, үзенә дә хыянәт итмәгән. Менә ул – халкыбызның дингә, аның күркәм дини йолаларына, милли гореф-гадәтләренә һәм үз-үзенә тугрылыгы. Менә ул – күп гасырлар илсез-җирсез, ирек-мөстәкыйльсез, хурлык-мәсхәрәдә көн күрсә дә, һәрчак үзе булып калган татарымның бөеклеге! Мәңге яшә, халкым.

Рәис САФИН,
Казан.

БАКЧАЧЫГА

РОЗА ГӨЛЕМ...

Бүген һәр бакчада диярлек роза чәчәге үстерелә. Чәчәкләр патшабикәсе саналган роза нәзберек гөлләр рәтенә керә, шуңа да ул үзенә шактый игътибар таләп итә.

Чәчәккә бөреләнгән чагында аңа бигрәк тә үсемлек бетләре (тля) ияләшә. Колонияләр булып роза куагының ботакларына, яфракларның аскы өлешенә урнашалар да алардагы сокны суырып, тиз арада үсеп үрчи дә башлыйлар. Алар һөҗүм иткән куаклар начар үсә, яфраклары бөтерелеп килә һәм коела, чәчәк бөреләре ачылмый да кала. Үсемлек бетләре ашаган куак кышкы салкыннарга да тиз бирешә. Алардан котылу өчен, кайбер бакчачылар керосинга су кушылган эретмә файдалана. Ун литр суга 2 грамм керосин салып болгатасың. Түбәндәге төнәтмә дә файдалы. 300 грамм ваклап туралган суган яки сарымсакка 400 грамм помидор яфрагын өч литрлы банкага тутырабыз. Су кушып, алты сәгатькә җылы урынга куябыз. Соңыннан төнәтмәне яхшылап болгатып, марля аша сөзәбез дә ун литрлы чиләккә бушатабыз. Чиләк тулганчы су кушабыз. Төнәтмә үсемлек ботакларына яхшылап ябышып калсын өчен, 40 грамм сыек сабын кушабыз. Куакларны әлеге төнәтмә белән җиде көн саен биш тапкыр эшкәртәбез.

Роза гөлләре өчен тагын бер куркыныч корткыч – пәрәвез талпаны. Ун литр суга 30 грамм карбофос салып сипсәгез, пәрәвез талпанын да җиңәрсез.

Майдан алып августкача очып йөрүче бронзакның да (чәчәк серкәләре белән тукланучы коңгызларның бер төре) күзе роза чәчәгенә төшми калмый. Ул чәчәкләрнең таҗларын ашый. Бигрәк тә ачык төстәге чәчәкле куакларга ияләшә ул. Аны исә иртән, чәчәкләрдә бер селкенмичә утырган вакытларында җыеп алырга кирәк.

Роза гөле авыруларга да тиз бирешүчән. Әйтик, ончыл чык дигән гөмбә авыруына. Әлеге авырудан түбәндәге катнашма булыша: бер аш кашыгы содага бер бал кашыгы савыт-саба юа торган сыеклык, бер аш кашыгы үсемлек мае, бер төймә эретелгән аспирин һәм 4,5 литр су салып, куакка сибәбез.

Ончыл чык төшкән куакның яфраклары саргая, шиңә башлый. Тәҗрибәле бакчачылар күгәргән печәннән ясалган сыеклык та куллана. Бурсыган печән өстенә су салабыз да ике-өч тәүлек тотабыз. Соңыннан өч тапкыр сибәбез. Бер атна сибәбез, бер атна ял иттерәбез. Шул рәвешле алты атнага сузыла. Ончыл чыкка каршы тагын бер чара: ун литр суга ун мл зеленка, ике литр сөт һәм биш грамм мочевина салып, килеп чыккан сыеклыкны үсемлеккә сибәбез. Сезон эчендә өч тапкыр кабатларга мөмкин, шулай ук атналап чиратлаштырасы була.

Моннан тыш, язын һәм көзен куак тирәсенә агач көле дә сибәргә кирәк (бер квадрат метрга 100-120 грамм исәбеннән).

Кара тап (марсонина) дигән гөмбә авыруы шулай ук роза куагы өчен куркыныч тудыра. Аны тану авыр түгел, куакның яфракларында төрле зурлыктагы кара-коңгырт таплар барлыкка килә. Ул бигрәк тә җәйнең икенче яртысында күренә башлый. Кайбер очракларда яфраклар бөтенләй каралып китеп кибәләр һәм коелалар. Споралары, гөмбәчекләре яфракларда калып кышлый да. Кара таптан котылу өчен, яфракларын җыеп алып яндырырга кирәк.

Әгәр дә роза яфракларында сары-әфлисун төсендәге таплар күренсә, бу – тутык авыруы (ржавчина) таралган дигән сүз. Әлеге авыру бигрәк тә җылы һәм дымлы яз килгәндә була. Аның аркасында чәчәкнең вегетатив органнары функциясе бозыла. Мондый очракта зарарланган яфракларын, бөреләрен җыеп яндырыгыз. 100 грамм кер сабынына 9 литр кайнар су салабыз. Икенче бер савытта бер литр суда ун грамм бакыр купоросын эретәбез. Ике эремәне бергә кушып, куакка сибәбез. Ясалган катнашманы тиз арада сибәргә кирәк, югыйсә ул катып кала.

Тагын бер киңәш: август ахыры-сентябрь башында роза куагына суны күп сипмәскә кирәк. Дым күп булгач, ул тагын да үсеп китеп, чәчәккә бөреләнә, әмма алар өлгерми кала һәм салкынга тиз бирешә.

Гадәти җәй көннәрендә суны атнага бер тапкыр сибегез. Җәй эссе килсә, атнага ике тапкыр да ярый. Нормасына килгәндә, бер куак төбенә – бер чиләк җылы су. Суны яфракларына тидермичә, тамырына сибәргә тырышыгыз.

Энҗе ГАФУРОВА,
Татар төбәкара ветеринария лабораториясе федераль дәүләт бюджет учреждениесе.

КАЗАН БУЙЛАП

Харалы күл

Шәһәребезнең Мулланур Вахитов урамында (Казан дәүләт энергетика университеты янында) «Харалы күл» («Харовое озеро») дигән парк урнашкан. Күпләребез ул тирәдән узып йөри торгандыр.

Әлеге сазлыклы урынны күмәргә дигән сүз чыккач, 2013-2014 елларда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов анда парк булдырырга карар кылды. Моны әйләнә-тирәдә яшәүчеләр дә хуплады һәм озак көттермичә, эшкә дә керештеләр. Шулай итеп, «Харалы күл» сакланып калды, андагы үсемлекләр, кошлар, хайваннар, балыклар зыян күрмәде.

Ни өчен күлнең исеме шундый сәер соң? Баксаң, бу күлдә безнең якларда сирәк очрый торган хара исемле суүсем күпләп үсә икән. Гади хара – макроскопик суүсем, 15-20 см биеклектә, карасу яшел төстә. Безнең якларда күпләп үсә торган нарат үләненә (наратбашка) охшаган. Бу үсемлек «Кызыл китап»ка кертелгән. Татарстанның өч күлендә һәм Чувашстан Республикасында харалар бар.

Гади хара суүсеменең яшь, йомшак үсентеләре балыкларга азык булып тора. Үсентеләр арасында вак балыклар яшеренә. Швейцариядә мондый суүсемнәр шактый күп булганлактан, аларны ашлама буларак та файдаланалар. Дөньяда хара суүсемнәренең якынча 300 төре билгеле.

«Харалы күл»дә төрле балыклар үрчи, әмма аларны кармакка гына тотарга рөхсәт ителә. Шулай ук бу күлне бакалар, тритоннар, су күселәре дә үз иткән. Камыш белән уратып алынган күлдә кыр үрдәкләре дә шактый. Күл буендагы камышлыкта оя ясап, үрдәкләр бәпкә чыгара. Алар өчен күл уртасында «түбәле йорт» та ясап куелган. Монда килүчеләр, күл эченә кертеп ясалган күпергә кереп, ул үрдәкләрне сыйларга ярата. Мондый сыйга акчарлаклар да шат. Паркта ала карга, саесскан, миләш чыпчыклары да җитәрлек.

Паркның читендә балалар мәйданчыгы төзелгән. Бирелә чисталык күзгә ташлана. Өмәләр вакытында бик күпләр булышырга килгән. Паркны тагын да матурлап, кешеләрне күбрәк җәлеп итәрлек дәрәҗәгә җиткерәсе иде.

Нияз БИШБАЛТА,
Казан.

Җелеккә үткән «офсайд»

Тамашачы матч башланырга ике сәгать кала ук стадионга агылды. Буш урыннар берән-сәрән генә күренде. Җанатарлар үз эшен «бишле»гә башкарды. Үзебезнең командабулмаса да, стадионда утырган 34 372 кеше футболчыларның һәр хәрәкәтен көчле эмоцияләр белән үзенчә шәрехләде.

Алисә САБИРОВА

Аеруча Португалия уенчысы Роналду Казан тамашачысының мәхәббәтен яулады, әйтерсең лә барысында да «роналдумания» чире башланган. Ләкин мексикалылар да матчта ятсынмады. Аларны да стадион көчле авацияләр белән каршылады. Кайсы як капкасына гол керүгә карамастан, халык гөж килде, чын күңелдән шатланды. Ни дисәң дә, «Казан-Арена»да тарихи вакыйга бара. Дөнья дәрәҗәсендәге матч алдыннан «Казан егетләре»нең «Тала-тала», Василә Фәттахованың «Туган як» җырларының яңгырап торуы татарларның күңелендә тагын да горурлык хисе уятты. Казан янә үзенең спорт башкаласы булуын дәлилләде.

Бу матч Португалия командасына икеләтә авыр бирелде. Шимбә көнне туган илләрендә коточкыч хәл булды. Педроган-Гранди бистәсендә чыккан янгында 57 кешенең гомере өзелде. Португалия спортчылары Кубоктагы беренче уенга матәм тасмасы белән чыкты. Уен исә бер минут тынлык белән башланды. Моның өчен ил җыелмасы ФИФАдан махсус рөхсәт алган. Шул рәвешле, спортчылар янгында һәлак булганнарның якыннарының кайгысын уртаклашты.

«Реал»ның йолдызлы спортчысы Криштиану Роналдуның да салым түләмәү аркасында килеп чыккан җәнҗалы җыелманың кәефен какшаткан, күрәсең. Төрле имеш-мимешләргә ышансаң, футболчы командадан китәргә җыена. Аның өчен инде Кытай елына 100 миллион сум акча түләргә риза икән.

Уен башында португалиялеләрнең «йокымсыравы» күренеп торды. Туп белән күбрәк Мексика командасы идарә итте. Криштиану Роналду белән Нани уенның беренче 15 минутында әллә ни куандырмады. Соңгысына, җитмәсә, эләкте дә – Мексика уенчысы аның башына «менеп төште», ә икенче таймда Нанины бөтенләй икенче уенчыга алыштырдылар. Ул җыелмадан китәргә җыена икән.

Бик итагатьле генә башланган матч беренче тайм ахырына кыз-ганнан-кызды. Португалиялеләр дә «уянып», беренче голны кертүгә ирешә, ләкин зур тырышлыклар белән капкага бернечә тапкыр һөҗүмнән соң кергән тупны хөкемдар санамады. Голны видеоассистентлардан караганнан соң – «офсайд» дип игълан иттеләр. Мондый әйбер Конфедерацияләр Кубогында беренче тапкыр күзәтелде.

Озак та үтмәде, португалиялеләр кабат һөҗүмгә күчте. Роналдуның тарихи пасыннан соң Рикарду Куарежма буш капкаларга беренче – бу очракта инде чын голны кертте. Мексикалылар Роналдуның бераз туп белән уйнавын көтте, ахры, шуңа да, үз капкаларын саклыйсы урында,катып калдылар. Нәтиҗәдә – беренче гол. Роналдуның әлеге кыланышы көндәшләрнең ачуын чыгарды. Матчның 42нче минутында Чичарито (Хавьер Эрнандес), баш белән бәреп, гол кертте. Мондый голларны футболчы чикләвек ваткан кебек кенә бәрә шул.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

РОССИЯ ҖЫЕЛМАСЫ КАТНАШАЧАК МАТЧ КӨННӘРЕ

21 июнь
РОССИЯ – ПОРТУГАЛИЯ
Башлана: 18.00
Спартак стадионы (Мәскәү)

24 июнь
РОССИЯ – МЕКСИКА
Башлана: 18.00
«Казан-Арена» (Казан)

Матчның икенче өлешендә футболчылар саграк уйнады. Инде ике команда да көндәшенең көчен чамалый, шуңа да артык хәрәкәтләр ясамаска тырыша. Бары тик соңгы 15 минутта гына уен кабат җанланды. Португалия уенчысы Седрик Суареш, тырышып-тырмашып, икенче гол кертте. Инде җиңделәр генә дигәндә, Эктор Морено уенның исәбен тигезләп куйды. Шулай итеп, Португалия – Мексика арасындагы матч 2:2 исәбе белән тәмамланды.

Мондый кызу уенны «Казан-Арена»ның әле күргәне юк иде. Казанлыларның яраткан уенчысы Криштиану Роналду исә матчның иң яхшы футболчысы дип танылды. Бөтендөнья тамашачысы тавыш бирү нәтиҗәсендә ул «BUD AF Man of the Match» бүләгенә ия булды.

Хәзер Россия җыелмасы А группасында беренчелектә бара. Португалия белән Мексика кебек чемпионнар уенын карагач, безнекеләргә Кубокта җиңү өчен могҗиза гына ярдәм итәр кебек.

Сүз уңаеннан, Конфедерацияләр Кубогы мондый форматта соңгы тапкыр үткәрелергә мөмкин. Ул тагын да масштаблырак булачак. Татарстанның яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов, Казанда Конфедерацияләр Кубогы башка кабатланмас, дип белми әйтмәгән икән.

ФИФА президенты да, Роналду да Казанның әзерлеген югары бәяләгән, ди шәһәр мэры Илсур Метшин.
– Мин кичә ФИФА президенты Джанни Инфантино белән сөйләштем. Ул стадионны гына түгел, Казанның әзерлеген дә уңай бәяләде. Португалиянең футбол Федерациясе президенты «Рубин» базасын мактады. «Рубин» Португалия командасы әзерләнгән иң яхшы базаларның берсе булуын ишетү күңелле, – ди Илсур Метшин. Роналду да Татарстан башкаласыннан таң калган.
– Роналду – дөнья буйлап йөрүче кеше. Безнең кунакчыллык, җанатарларның җылы каршы алуы ошаган аңа. Мин Казан халкына шуның өчен рәхмәтлемен. Һәр зур чара – шәһәр хуҗалыгына бәйле мәсьәләләрне тагын бер кат карап чыгу чарасы. Һәр зур чара безне яңа дәрәҗәгә күтәрә, – диде Илсур Метшин.

Футбол җанатарлары «Кол Шәриф»не үз иткән

Конфедерацияләр Кубогы вакытында Казан Кремленә көн саен 9-11 мең кеше килә. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры Зилә Вәлиева хәбәр итүенчә, бу – гадәти көннәрдән зуррак сан. Узган елны 18 июнь көнне музейга 7 мең кеше килсә, быел халык саны 9 меңнән артып киткән. Казан кунаклары Кремль территориясенә тәүлек дәвамында килә ала. Җомга көнне исә музейлар кичке тугызга кадәр эшли.

– Кунакларга, иң беренче чиратта, Казан атмосферасын күрсәтергә тырышабыз. Туристлар аеруча да «Кол Шәриф» белән Благовещение соборына яратып йөри. Казан буйлап экскурсияләрне дә үз итә. Көндез вакытлары булмаганнар «Төнге Казан» экскурсиясенә языла ала. «Гасыр даһие» күргәзмәсе дә туристларның игътибар үзәгендә. Матч көнне бирегә Португалия спикерлары килде. Туристлар күбрәк татарларның кемлеге, килеп чыгышы белән бик кызыксына, – ди Зилә Вәлиева.

Казан, Татарстан рухын аерым бер гаилә тарихында караудан да кызыграк ни булсын?! «Манеж» күргәзмәләр залында «Гаилә тарихы – Республика тарихы» дигән күргәзмәдә шәһәр кунаклары Сәйдәшевләр, Михеевлар, танылган табиблар, нефтьчеләр, дары заводында 300 ел эш стажы булган гаилә тарихлары белән таныша. Идел буенда яшәүчеләрнең туй, дәвалау йолалары шулай ук кызыксыну уята. Күргәзмәләргә билетларны Кремльнең һәр музееннан алып була.

Казан Кремленә Роналду да килергә тиеш булган.

– Без дә Роналдуны көттек, ләкин эш көне тыгыз булу аркасында килә алмады. Универсиада вакытыннан чыгып әйтәм: спортчылар ярыш узган шәһәрне өйрәнергә ярата. Мөмкинлекләре булса килерләр иде,– ди Зилә Вәлиева.

Кубок вакытында шулай ук барлык театрларда да сезон озынайтылды. «Әкият» курчак театры, Яшь тамашачы театры футбол бәйрәменә ике премьера әзерләгән. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры исә кунакларны «KAZAN CLASSIC FEST» фестивалена көтә.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

Бу санның тиражы – 1580. Гомуми тираж – 5955.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 726. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы